**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 декабрь № 954

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 30 апрель, 289 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 30 апрель, 289 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 13 декабрь, 985 нче; 2015 ел, 20 март, 179 нчы; 2015 ел, 15 сентябрь, 677 нче; 2015 ел, 9 декабрь, 931 нче; 2016 ел, 31 май, 362 нче; 2016 ел, 21 сентябрь, 669 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлының дүртенче абзацында «187» саннарын «214» саннарына алмаштырырга;

Программаның 2 бүлегендә:

егерме дүртенче абзацта «187» саннарын «214» саннарына алмаштырырга;

Программаның 2 бүлегендәге 2.3 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«2.3. «2014 – 2020 елларга территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру» ярдәмче программасы**

Ярдәмче программаны эшләү өчен нигезләр: Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып алырлык һәм уңайлы торак белән тәэмин итү һәм торак-коммуналь хезмәтләр сыйфатын күтәрү буенча чаралар турында» 2012 ел, 7 май, 600 нчы Указы, «Торак төзелешен үстерүгә булышлык күрсәтү турында» 2008 ел, 24 июль, ФЗ-161 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 ел, 17 декабрь, 1050 нче карары белән расланган «Торак» федераль максатчан программасының «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларын стимуллаштыру» ярдәмче программасы.

Ярдәмче программаның төп максаты – территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә торак төзелешендәге инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар тудыру.

Ярдәмче программа кысаларында торак төзелешен үстерү программаларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр алу буенча чаралар тормышка ашырылачак, әлеге субсидияләр түбәндәгеләргә файдаланыла ала:

экономияле класслы торак төзелеше өчен күздә тотылган, шулай ук 3 һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә бирелә торган җир кишәрлекләрен инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин итү максатларына Россия кредит оешмаларында заемга алучылар алган кредитлар буенча процентларны түләү өчен чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплауга;

экономияле класслы торак төзелешен күздә тоткан территорияләрне комплекслы үзләштерү проектларын тормышка ашыру кысаларында социаль инфраструктура объектларын төзүгә (төзекләндерүгә);

массакүләм аз катлы һәм күпфатирлы экономияле класслы торак төзелә торган микрорайоннарда автомобиль юлларын төзүгә (төзекләндерүгә);

энергиядән нәтиҗәле файдалана һәм энергия саклый торган төзелеш материаллары, конструкцияләр һәм эшләнмәләр чыгара торган энергия нәтиҗәле төзелеш индустриясе предприятиеләрен төзекләндерүгә һәм (яки) төзүгә Россия кредит оешмаларында заемга алучылар алган кредитлар буенча процентларны түләү өчен чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплауга.

Федераль милектә булган нәтиҗәле файдаланылмый торган җир кишәрлекләрен, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен хуҗалык кулланышына кертү чаралары кысаларында мондый җир кишәрлекләрен билгеләү эше, әлеге җир кишәрлекләрен алга таба файдалану мәсьәләсен җентекләп өйрәнү күздә тотыла.»;

Программага кушымтага:

8 графада «Яшь гаиләләргә экономияле класслы торак сатып алуга социаль түләүләр бирү» юлында «50» саннарын «77» саннарына алмаштырырга;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән

тәэмин итү» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлының икенче абзацында «50» саннарын «77» саннарына алмаштырырга;

Ярдәмче программаның 5 бүлегендә:

сигезенче абзацта «336» саннарын «363» саннарына алмаштырырга;

Ярдәмче программага 1 нче кушымтада:

8 графада «Ярдәмче программада катнашучы яшь гаиләләрне исәпкә алуны оештыру» юлында «50» саннарын «77» саннарына алмаштырырга;

8 графада «Яшь гаиләләргә бүленгән социаль түләүләрне бирү өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр күчерү» юлында «50» саннарын «77» саннарына алмаштырырга;

Ярдәмче программага 3 нче кушымтада:

1 нче пунктның беренче абзацында, 54 нче пунктның «а» пунктчасында «2011 елның 1 гыйнварына кадәр алынган» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 нче пунктның бишенче абзацында, 9 нчы пунктның бишенче абзацында, 15 нче пунктның беренче абзацында, 16 нчы пунктның беренче абзацында, 47 нче пунктның беренче абзацында, 48 нче пунктның икенче абзацында «2011 елның 1 гыйнварына кадәр алынган» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Яшь гаилә өчен торак урынның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгеләгәндә, социаль наем шартнамәләре буенча яшь гаилә әгъзалары биләгән барлык яшәргә яраклы торак урыннарның һәм (яки) яшь гаилә әгъзаларының милек хокукындагы торак урыннарының һәм (яки) торак урын (торак урыннар) өлешенең гомуми мәйданының кушылган күләме исәпкә алына.»;

16 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ипотека торак кредиты (заемы) акчасыннан файдаланып сатып алынган (төзелгән) торак урынга милек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамә күчермәсе яки Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (торак йорт төзелеше тәмамланмаганда Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы тарафыннан расланган төзелешкә документлар тапшырыла);

кредит шартнамәсе (заем шартнамәсе) күчермәсе;»;

28 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы яшь гаиләләр – тиешле елда социаль түләүләр алуга дәгъвачылар исемлеген раслаган көннән соң 10 календарь көн эчендә җирле үзидарә органнарына яшь гаиләләр – тиешле елда социаль түләүләр алуга дәгъвачыларның расланган исемлегеннән өземтәне җиткерә.»;

36 нчы пунктның беренче абзацында «30 календарь көн» сүзләрен «15 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

43 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«43. Счет белән эш итүче социаль түләүдән теләсә нинди физик һәм (яки) юридик затлардан бер (берничә) торак урын сатып алу өчен яки билгеләнгән санитария таләпләренә һәм техник таләпләргә туры килә торган, акча буенча хезмәт күрсәтүгә сайланган банктан ипотека торак кредиты җәлеп итү юлы белән анда торак урын сатып алына (төзелә) торган, даими рәвештә яшәү өчен сайланган торак пункт шартларына карата уңайлаштырылган, Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы билгеләгән тәртип (норматив документ) нигезендә торак төзелеше объекты төзү өчен файдаланырга хокуклы.

Сатып алына торган торак урын (төзелә торган торак төзелеше объекты) җирле үзидарә органы яшь гаиләне планлаштырылган елда социаль түләү алу теләген белдергән яшь гаиләләр исемлегенә керткән муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан булырга тиеш.

Социаль түләү күләмен хисаплаганда исәпкә алынган яшь гаиләнең һәр әгъзасына исәпләгәндә сатып алына торган торак урынның (төзелә торган торак төзелеше объекты) гомуми мәйданы, торак сатып алу (төзү) урынында торак урыннарга мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу максатларында, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданының исәпкә алынган нормасыннан кимрәк була алмый.

Социаль түләүдән торак кредитлары, шул исәптән ипотека, яисә торак урын сатып алуга яки торак йорт төзүгә торак заемнары буенча төп сумманы каплау һәм процентларны түләү өчен файдаланган очракта, әлеге кредитлар яки заемнар буенча йөкләмәләрне үтәү вакыты чыкканга башка процентлар, штрафлар, комиссияләр һәм пенялардан тыш, яшь гаиләнең һәр әгъзасына исәпләгәндә сатып алына торган торак урынның (төзелә торган торак төзелеше объекты) гомуми мәйданы әлеге торак урынга (торак йортка) милек хокукын дәүләт теркәвенә алган көнгә, торак урын сатып алу яки торак йорт төзү урынында торак урыннарга мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу максатларында, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданының исәпкә алынган нормасыннан кимрәк була алмый.

Яшь гаиләләр – Ярдәмче программада катнашучылар, торган торак урын сатып алу (торак төзелеше объекты төзү) максатларында, үз акчаларын, ана (гаилә) капиталы акчасын, шулай ук тиешле лицензиясе булган оешмалар һәм (яки) физик затлар бирә торган кредитлар яки заемнар акчасын җәлеп итә алалар.

Сатып алына торган торак урынны (төзелә торган торак төзелеше объектын) сайлаганнан соң, яшь гаилә – Ярдәмче программада катнашучы, Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы тарафыннан расланган торак урынга (төзелә торган торак төзелеше объектына) документлар күчермәләрен теркәп, җирле үзидарә органы белән торак урын сатып алу (торак төзелеше объекты төзү) турында килешү төзи.»;

44 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«44. Сатып алына торган торак урынга (торак йорт төзелешенә) түләү өчен счет белән эш итүче банкка банк счеты шартнамәсен, торак урынга шартнамә яки төзелеш тәртибе шартнамәсе, сатып алына торган торак урынга (төзелгән торак йортка) милек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамә яки Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә

һәм бирелә торган социаль түләү күләменнән артык булган өлештә сатып алына торган торак урын (төзелә торган торак йорт) өчен түләүгә акча җитәрлек булуын раслый торган документларны тапшыра.»;

47 нче пунктның «б» һәм «в» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) кредит шартнамәсе (заем шартнамәсе);

в) сатып алынган торак урынга милек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамә яки Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә – торак йорт төзелеше тәмамланмаганда;»;

50 нче пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) кооперативның торак урынга милек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамә күчермәсе яки яшь гаилә – Ярдәмче программада катнашучы өчен сатып алынган Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;»;

51 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«51. Банк әлеге Кагыйдәләрнең 44 – 47 нче һәм 50 нче пунктларында каралган документларны алган көннән соң биш эш көне эчендә аларда булган мәгълүматларны тикшерүне гамәлгә ашыра, ул үз эченә сатып алына торган торак урынның (төзелә торган торак йортның) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган торак йортларның экономияле класслы торакка керү шартларына туры килүен тикшерүне ала.»;

Ярдәмче программага 5 нче кушымтада 5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) теркәлгән урын буенча били торган торак урынга, шулай ук соңгы 5 елда милектә булган торак урыннарга хокукны билгели торган документлар (социаль наем шартнамәсе, хосусыйлаштыру шартнамәсе, сату-алу шартнамәсе, бүләк итү турында шартнамә, милек хокукын теркәү турында шаһәдатнамә яки Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә һ.б.) күчермәләре, индивидуаль торак төзелеше объектларында яшәүчеләр өчен – әлеге объектка техник паспорт;»;

«2014 – 2020 елларга территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру» ярдәмче программасында:

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ярдәмче программаның төп максаты һәм бурычлары,
ярдәмче программа чаралары, соңгы нәтиҗәләр тасвирламасы,
аны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары

Ярдәмче программаның максаты булып территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә торак төзелешендәге инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар тудыру тора.

Ярдәмче программаның максатына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү зарур:

торак төзелеше программаларын, шул исәптән «Россия гаиләсе өчен торак» программасы кысаларындагы проектларны тормышка ашыру;

социаль һәм инженерлык инфраструктураларын, экономияле классны торак төзелешенә алып килә торган автомобиль юлларын үстерү;

федераль милектә булган нәтиҗәле файдаланылмый торган җир кишәрлекләрен, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен хуҗалык кулланышына кертү;

нәтиҗәле шәһәр төзелеше сәясәтен үткәрүгә, экономияле классны торак төзелеше өчен шартлар тудыруга, торак төзелеше базарында демонополизациягә һәм конкурентлыкны үстерүгә стимуллаштыру.

Уңайлы шәһәр мохите һәм авыл җирлекләре мохите формалаштыру өчен Ярдәмче программа чаралары заманча архитектура-киңлек ягыннан оештыру таләпләренә җавап бирә торган төзелеш эшчәнлеген стимуллаштыруга, әйләнә-тирә мохит торышын яхшырту бурычларына, дөньякүләм экология стандартларына юнәлдерелгән булырга тиеш.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруны вакытыннан алда туктату шартлары булып вакытыннан алда Ярдәмче программа максатына ирешү һәм бурычларын үтәү, шулай ук дәүләт торак сәясәте юнәлешләрен үзгәртү тора.

Ярдәмче программа кысаларында торак төзелешен үстерү программаларын, «Россия гаиләсе өчен торак» программасы проектларын кертеп, гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр алу буенча чаралар тормышка ашырылачак, әлеге субсидияләр түбәндәгеләргә файдаланыла ала:

экономияле классны торак төзелеше өчен күздә тотылган, шулай ук 3 һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә бирелә торган җир кишәрлекләрен инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин итүгә Россия кредит оешмаларында заемга алучылар алган кредитлар буенча процентларны түләү өчен чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплауга;

экономияле классны торак төзелешен күздә тоткан территорияләрне комплекслы үзләштерү проектларын тормышка ашыру кысаларында социаль инфраструктура объектларын (мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф учреждениеләре, сәламәтлек саклау учреждениеләре) төзүгә (төзекләндерүгә);

массакүләм аз катлы һәм күпфатирлы экономияле классны торак төзелә торган микрорайоннарда автомобиль юлларын төзүгә (төзекләндерүгә);

энергиядән нәтиҗәле файдалана һәм энергия саклый торган төзелеш материаллары, конструкцияләр һәм эшләнмәләр чыгара торган энергия нәтиҗәле төзелеш индустриясе предприятиеләрен төзекләндерүгә һәм (яки) төзүгә Россия кредит оешмаларында заемга алучылар алган кредитлар буенча процентларны түләү өчен чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплауга.

Ярдәмче программа кысаларында оештыру чаралары түбәндәгеләргә юнәлдерелгән булачак:

торак төзелешендә административ каршылыкларны киметү өчен шартлар тудыру, конкурентлыкны үстерү һәм төзүчеләрнең кредит ресурсларыннан файдалана алу мөмкинлеген киңәйтү, шәһәр төзелеше контроле һәм монополиягә каршы контроль өлкәсендә чараларны тормышка ашыру;

шәһәр округлары һәм шәһәр җирлекләренең торак төзелешен тәэмин итү өчен кирәкле коммуналь, транспорт һәм социаль инфраструктураларын комплекслы үстерүнең оештыру механизмнарын гамәлгә кертүгә булышлык күрсәтү;

проектларны тормышка ашыру өчен кредит һәм инвестиция акчаларын җәлеп итүнең оештыру механизмнарын гамәлгә кертү.

Оештыру чаралары өстәмә бюджет акчасы бирүне таләп итми.

Федераль милектә булган нәтиҗәле файдаланылмый торган җир кишәрлекләрен, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен хуҗалык кулланышына кертү кысаларында мондый җир кишәрлекләрен билгеләү эше, алардан алга таба файдалану мәсьәләсен хәл итү күздә тотыла.

Ярдәмче программа 2014 – 2020 елларда тормышка ашырыла.

Тормышка ашыруның ике этабы күздә тотыла:

I этап: 2014 – 2015 еллар;

II этап: 2016 – 2020 еллар.

Программа чараларын тормышка ашыру 2015 ел йомгаклары буенча экономияле класслы торакны гамәлгә кертү өлешен торакны гамәлгә кертүнең гомуми еллык күләмендә 17 процентка кадәр арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк, 2020 ел йомгаклары буенча экономияле класслы торакны гамәлгә кертү өлеше торакны гамәлгә кертүнең гомуми еллык күләмендә 20 процент тәшкил итәчәк.»;

ярдәмче программаның 4 бүлегендә:

икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруның кредитлар буенча процентларны түләүгә чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплауны күздә тоткан финанс механизмнары инженерлык инфраструктурасын үстерү һәм энергиядән нәтиҗәле файдалана һәм энергия саклый торган төзелеш материаллары, конструкцияләр һәм эшләнмәләр чыгара торган энергия нәтиҗәле төзелеш индустриясе предприятиеләрен төзекләндерү һәм (яки) төзү проектларын финанслау өчен банк кредит ресурсларын җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруның социаль инфраструктураны үстерүне һәм автомобиль юллары белән тәэмин итүне күздә тоткан финанс механизмнары Татарстан Республикасының һәм җирле үзидарә органнарының торак төзелеше проектларын тормышка ашыру буенча вәкаләтләрен үтәүгә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән.»;

1 таблицадан соң икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль милектә булган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен торак төзелеше өчен хуҗалык кулланышына кертү Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Торак төзелешен үстерүгә булышлык күрсәтү федераль фонды арасындагы үзара эш итү һәм хезмәттәшлек турында 2014 елның 29 декабрендәге К-29 нчы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 таблица

## Федераль милектә булган нәтиҗәле файдаланылмый торган җир кишәрлекләрен хуҗалык кулланышына кертү

| Т/с | Җир кишәрлегенең кадастр саны | Җир кишәрлеге урнашкан урын | Гомуми мәйданы, гектар | Рөхсәт ителгән файдалану төре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **Хуҗалык кулланышына кертелгән җир кишәрлекләре** | | | | |
| 1 | 16:50:171126:40 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Идел буе районы, Оренбург тракты ур. | 7,2909 | 3 – 5 катлы күпфатирлы торак йортлар |
| 2 | 16:50:171125:18 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Идел буе районы, Оренбург тракты ур. | 3,9956 | 3 – 5 катлы күпфатирлы торак йортлар |
| 3 | 16:24:150302:120 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | 14,3083 | 3 каттан югары булмаган күпфатирлы торак йортлар |
| 4 | 16:24:150302:119 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге, Усад авылы | 36,134 | торак төзелеше |
| 5 | 16:50:171125:19 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Идел буе районы, Оренбург тракты ур. | 2,7675 | күпфатирлы торак йортлар – махсус билгеләнештәге зонада (зона коды – ДЗ) торак төзү максатларында территорияләр-не комплекслы үзләштерү өчен |
| 6 | 16:24:150304:119 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге, Усад авылы | 25,0 | торак төзелеше |
| 7 | 16:24:150302:118 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | 63,0799 | торак төзелеше |
| 8 | 16:50:090565:101 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Горсовет ур. | 0,75 | торак төзелеше |
| 9 | 16:24:150304:120 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге, Усад авылы | 179,76 | торак төзелеше |
| 10 | 16:50:171201:284 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Идел буе районы, Оренбург тракты ур. | 29,5 | торак төзелеше |
| 11 | 16:24:000000:235 | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл | 313,51 | технопарк төзү өчен |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | җирлеге | | |
| 12 | Җир кишәрлеге өлеше 16:16:120601:481 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Константиновка авылыннан 500 метрга төньяк-көнбатышка | 28,9 | торак төзелеше |
| **Аларга карата хуҗалык кулланышына кертү турында карар кабул ителгән җир кишәрлекләре** | | | | |
| 13 | 16:16:120601:482 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Константиновка авылыннан 500 метрга төньяк-көнбатышка | 117,67 | күпбалалы гаиләләргә бирү өчен |
| 14 | 16:50:171201:51 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Идел буе районы, Оренбург тракты ур. | 2,91 | территорияләрне башка үстерү |
| 15 | 16:16:000000:330 | Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Дачное авыл җирлеге | 521,5 | күпбалалы гаиләләргә бирү өчен |
| 16 | 16:50:171201:282 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Идел буе районы, Ферма-2 ур. | 4,36 | торак төзелеше максатларында комплекслы үзләштерү өчен |
| 17 | 16:50:000000:13300 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Академик Губкин ур. | 11,27 | комплекслы үзләштерү өчен, шул исәптән торак төзелешенә |
| **Хуҗалык кулланышына кертү өчен карап тикшерелә торган җир кишәрлекләре** | | | | |
| 18 | Җир кишәрлеге өлеше 16:16:120601:481 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Константиновка авылыннан 500 метрга төньяк-көнбатышка | 4,7 | карар кабул ителмәгән |
| 19 | 16:50:070404:41 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Идел буе районы, Даурия ур. | 0,7512 | карар кабул ителмәгән |
| 20 | 16:50:130209:9 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Казансу елгасының сул ярында | 2,2 | карар кабул ителмәгән |
| 21 | 16:50:170117:1 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Старое Победилово поселогы | 18,0дән 14,0 | карар кабул ителмәгән |
| 22 | 16:50:110701:109 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Гаврилов ур. | 21,148 | карар кабул ителмәгән |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 23 | 16:52:040205:19 | Татарстан Республикасы, Чаллы, Тынычлык проспекты | 12,7дән 7,0 | карар кабул ителмәгән |
| 24 | 16:16:080503:379 | Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау авыл җирлеге | 6,6дан 4,0 | карар кабул ителмәгән |
| 25 | 16:15:000000:1549 | Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Килди авыл җирлеге | 2327,0 | карар кабул ителмәгән |
| 26 | 16:50:130101:107 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Троицк урманы ур. | 14,2 | карар кабул ителмәгән |
| 27 | 16:50:110605:8 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Яңа Савин районы, Адоратский ур. | 1,07 | карар кабул ителмәгән |
| 28 | 16:50:110602:21 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Яңа Савин районы, Адоратский, Чистай, Четаев урамнары, Ф.Әмирхан проспекты чикләрендә | 2,7 | карар кабул ителмәгән». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\954.doc